# ӘДӘП ТӨБЕ – МАТУР ГАДӘТ

**Максат:** башка балалар белән аралашуда әдәплелеккә өйрәтү; бәйләнешле сөйләм телен үстерү; үз фикерләрен ачык, төгәл әйтә белү күнекмәләре формалаштыру өстендә эшне дәвам иттерү; мактанмау, масаймау, тупас булмау, кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәт сыйфатлары

тәрбияләү.

**Җиһазлау:** магнитофон, мәкальләр язылган карточкалар, “тылсымлы” сүзләр язылган карточкалар, рәсемнәр (гөл һәм кактус рәсеме).

**Дәреснең барышы**

1. Очрашканда кешеләр –
Олылар һәм кечеләр –
Бер-берсен сәламлиләр:
“Исәнмесез”, – диләр.

2. Очрашсалар бик иртә,
Бик матур теләк әйтә.
Нинди теләк? Кем әйтә?
Ул сүз ... хәерле иртә!

3. Күрешсәләр көндезен
Кышын, җәен, яз-көзен.
Нинди теләк әйткәнен
Кем белә? ... Хәерле көн!

4. Күрешсәләр алар кич
Сәлам бирми үтми һич.
Сәламләшү сүзләре
Булачак ... (Хәерле кич!).

– Исәнмесез, балалар! Бүген без сезне “Әдәплелек иле”нә сәяхәт итәргә чакырабыз. Хәзер без бер малай һәм кыз турында әкият карарбыз. Әкияттәге кыз белән малай әдәпле балалар микән? Әгәр дә алар тәртипсезләнә башласа, кул чабарсыз. Без аларга хаталарын аңлатырбыз. Әкиятне башлыйбыз.

**Тәмле сүз**

*(Бүлмәдә малай белән кыз уйнап утыра. Әби керә.)*

**Әби.** Мин тиз генә кибеткә барып кайтам. Сез тату гына уйнагыз. Тәмле телле, тәмле сүзле булыгыз. *(Әби китә).*

**Кыз.** Нинди була икән ул тәмле сүз? Син белмисеңме?

**Малай.** Белмим шул. Ул бит конфет та, прәннек тә түгел. Аны ашап карап та булмый бит.

**Кыз.** Сүзләр бик күп инде алар: эти, әни, ипи, матур, зур. Әби әйткән тәмле сүз нинди була икән ул?

**Малай.** Ярар, әби кайткач сорарбыз әле.

**Кыз.** Әйдә, әби кайтканчы бергә уйныйбыз.

**Малай.** Әйдә ат-ат уйныйбыз. Син ат буласың, мин сине йөртәм. На – на! *(чәченнән тарта)*

**Кыз** *(елый)*. Нигә минем чәчемнән тартасың? *(Балалар кул чабалар)*

**Алып баручы.** Кызларны рәнҗетергә, чәчләреннән тартырга ярамый. Гөлнур апа керә.

**Гөлнур апа.** Исәнмесез, дусларым!

**Кыз, малай.** *(бергә).* Исәнмесез, Гөлнур апа! Әйбәт кенә килеп җиттегезме?

**Гөлнур апа.** Бик яхшы килеп җиттем, балалар. Рәхмәт инде сезгә. Шуның өчен сезгә бүләк алып килдем.

**Кыз.** Рәхмәт, Гөлнур апа. Нинди матур курчак!

**Малай.** Бир әле, мин дә карыйм. *(Малай кызның курчагын тартып ала, тарткалаша башлыйлар)*

*Әби керә.*

**Әби.** Мин дә кайтып җиттем, балалар.

**Кыз.** Әбием, Гөлнур апа килде. Ул миңа курчак алып килде. Карале, нинди матур!

**Әби.** Әйе, бик матур. Бергә уйнагыз.

**Кыз.** Юк, уйнамыйм Айрат белән. Ул сугыша.

*(Балалар кул чабалар)*

**Алып баручы:** Әбиләр белән тупас сөйләшергә ярамый.

**Әби турында җыр**

1. Әбием күзлек кия,
Чәчләренә чал кунган.
Бер көн дә соңга калмый,
Иртүк тора йокыдан.
    Әбекәй, алтыным,
    Минем иң якыным.
    Яратам, яратам
    Мин аны!
2. Минем әби энемне,
Бәй-бәй итә, пәп итә.
Ул йокыдан торганда,
Мәмие пешеп җитә.
Әбекәй, алтыным,
Минем иң якыным.
Яратам, яратам
Мин аны!

**Кыз.** Әбием, гафу ит мине.

**Әби.** Ярый, гафу итәрмен. Бүтән алай сөйләшмәгез.

**Кыз, малай (бергә).** Без моннан соң тупас сөйләшмәбез.

**Кыз.** Хәзер мин тәмле телнең нәрсә икәнен беләм.

**Малай.** Мин дә беләм.

**Укытучы**. Балалар, ә сез тәмле, тылсымлы сүзләрне беләсезме?
*(Балалар тылсымлы сүзләр әйтәләр)*

- Хәзер **“Авыраяк**” әкиятен карап үтик.

**Укытучы.** Авыраяк озак йоклады. Менә ул уянды, урамга карады.
**Авыраяк.** Ура! Кар яуган. Әнкәй, минем чаңгыларым кая? Әнисе чаңгыларны табып бирде.
**Авыраяк.** Әнкәй, минем пальтом кайда? *(Пальтоны бик озак эзләделәр)*
**Авыраяк.** Әнкәй, әнкәй, минем бүрегем кайда? *(Авыраякның бүреге өстәл астында иде)*
**Авыраяк.** Әнкәй, әнкәй, минем бияләйләрем кайда?
**Әни.** Улым, әйберләреңне җыеп йөрергә кирәк.
**Авыраяк.** Уф, киттем мин әнием *(Авыраяк урамга чыкты, ә анда кар эрегән дә беткән)*.
**Укытучы**. Балалар, Авыраяк нинди малай, сезнең арада андый малайлар юкмы? Әниләрегезгә, әбиләрегезгә нинди матур сүзләр әйтәсез? *(Укучыларның җаваплары)*
Ә хәзер сезгә өйдә өйрәнеп килгән шигырьләрегезне сөйләрсез.

**1 нче укучы**.
***Ш.Галиев “Мин”***

Мин – Шәвәли,
Шук малай.
Үткен малай,
Ут малай.
Мин – бик уңган,
Өлгер мин,
Юк-бар белән
Көлдермим!
Бик тапкыр мин,
Җыйнак мин,
Мин,
Мин бик,
Тыйнак!
Мин!
**Укытучы.** Шәвәли нинди малай? *(Укучылар җавап бирә)*

**Н.Мәдияров “Инде мактанмас инде”**

Мактана Вил, күкрәгенә
Кулын куеп:
– Фәрит, минем сыбызгым бар,
Синеке юк.
Әйтә тагын, түшенә
Ул сугып:

– Фәрит, минем шарларым бар,
Синеке юк.
Түзми Фәрит, җавап бирә:
– Һәм, шулай ук,
Синең бит “... икелең” дә бар,
Минеке юк.

**М.Газизов “Рәхмәт”**

– Әхмәт, Әхмәт
Тырысымны бирче рәтләп!
Әхмәт әйтә:
– Рәфгатькә әйт!
– Рәфгать, Рәфгать!
Тырысымны бирче рәтләп!
Рәфгать әйтә:
– Рәхмәткә әйт!
– Рәхмәт, Рәхмәт!
Тырысымны бирче рәтләп!
Бирде Рәхмәт
Шундук рәтләп.
– Рәхмәт, Рәхмәт!

**Укытучы.** Малайларның кайсы сезгә ошады? Ни өчен?
*(Балаларның җаваплары тыңлана)*

**Укытучы.** (Б*аларга сүзләр язылган карточкалар тарата)*- Ә хәзер бу карточкаларны тактада ясалган гөл рәсемнәренә беркетергә кирәк. Матур сүзләрдән кәеф күтәрелә, ә тупас сүзләр, кактус энәләре кебек, авырттыра: рәхмәт, тупас, сау бул, мактанчык, исәнме, ялкау, хәерле көн, тәртипсез, гафу ит, бир, зинһар өчен, саран, сәлам, хуш.

**Тактадагы мәкальләрне уку, аңлату.**
Әдәп төбе – матур гадәт.
Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.
Яхшы сүз – җанга рәхәт

*Бүгенге кичәбезне матур җыр белән тәмамлыйбыз.*
(В.Чурагулова сүзләре, У. Рәшитов көе “Гөрләшеп яшик”)